КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 февраль г.Казань № 187

Бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре торак пункт чикләренә кертелергә йә бакчачылык территориясе чикләрендә яңа торак пункт төзелергә мөмкин булган таләпләрне раслау турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законның $4^{1}$ статьясындагы 4 өлеше һәм «Татарстан Республикасында гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге ТРЗ-35 номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре торак пункт чикләренә кертелергә йә бакчачылык территориясе чикләрендә яңа торак пункт төзелергә мөмкин булган таләпләрне расларга.
2. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 февраль, 187 нче
карары белән расланды

Бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре торак пункт чикләренә кертелергә йә бакчачылык территориясе чикләрендә яңа торак пункт төзелергә мөмкин булган таләпләр

1. Бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе чикләре алар кертелә торган торак пунктның чикләре белән чиктәш булырга тиеш.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясындагы 39 пунктында күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты параметрларына туры килә торган торак йортлар саны бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясендә йортларның гомуми саныннан кимендә 90 процент тәшкил итәргә тиеш.

3. Бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясенә карата Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «СНиП 2.07.01-89* Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү» дигән 42.13330 нчы санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 30 декабрендәге 1034/пр номерлы боерыгында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак пунктлары урамнары һәм юллары. Шәһәр төзелеше проектын ясау кагыйдәләре» кагыйдәләрен җыелмасын раслау турында» 2018 елның 1 августындагы 474/пр номерлы боерыгында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше проектын ясау буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карарында һәм шәһәр төзелеше проектын ясау буенча җирле нормативларда билгеләнгән проект ясауга һәм йортлар салуга карата таләпләрне үтәү.

4. Бакчачылык территориясе чикләрендә «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән таләпләргә туры килүне тәэмин иткәндә яңа торак пункт төзелергә мөмкин.